**Сәлимә ШӘРИПОВА,**
*«Ләйсән» әдәби иҗат*
*берләшмәсенең иң беренче әгъзасы*

## КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕМНӘН ИСТӘЛЕКЛӘР

Безнең Ташкичү авылында, сөргенгә куылган мулладан калган, яртылаш җиргә сеңгән ярым-җимерек йорт бар иде. Ул колхоз кәнсәләре хезмәтен үтәде. Шул йортның бер почмагын бүлеп, китапханә кебек нәрсә эмәлләделәр. Без, авыл яшьләре, көнозын басу-кырда, фермада эшләп арганнан соң, шунда ашкына идек. Һәркем алданрак барырга, санаулы гына булган китапны эләктереп калырга тырыша. Кулдан-кулга йөреп таушалып, ертылып беткән китапларны укып бетергәннән соң, бәрәңге измәсеннән клей ясап, ремонтлап, китапханәгә кире тапшыра идек. Ул чакларда язучыларга да, китапка да бер тылсымлы илаһи көч итеп, инанып карый идек. Шигырь язу чире шул елларда кабынды миндә. Батырчылыгым җитеп, «Коммунизм байрагы» газетасына беренче шигырьләремне җибәрдем. Озак та көттерми, газетаның баш мөхәррире Хәнәфи абый Маннаповтан уңай җавап килде. Бу хәбәр мине канатландырды. Ул шигырь юллары арасында мондый юллар бар иде:

Шофёр егет коштай очып,
Ашлык ташый басудан.
Тузан калдырып кала җил,
Узалмаган ачудан.

Тора-бара Хәнәфи Маннапов һәм анда эшләүче милли җанлы журналистлар Зәйнәп Җиһаншина, Заһидә Нәбиуллиналар әдәби түгәрәк оештырып җибәрделәр. Хәтеремдә, шул түгәрәкнең эше белән танышырга Казаннан шагыйрь Мәхмүт Хөсәен килгән иде. Ул, безнең авылга килеп, минем шигырьләрем турында авыл яшьләре белән әңгәмә корды. Безгә кунарга кайткач, төне буе миңа киңәшләрен бирде. Очрашу нәтиҗәсе итеп, Мәхмүт Хөсәен «Яшь шагыйрә энҗеләре» дигән исем астында, гәҗит тутырып, минем хакта мәкалә бастырды.

Әдәби түгәрәккә төрле төбәкләрдән «шигырь җене» кагылган егет-кызлар агыла башлады. Шау-гөр килеп шигырь укып, әңгәмә корганда, без җыелган иске салкын бина да зур, якты, җылы булып тоела иде. Иҗат белән шөгыльләнүче яшьләрне «әдәби түгәрәк» дигән исем генә канәгатьләндерми башлады. «Әдәби берләшмә» дип үзгәртергә булдык, ә исеменә килгәндә, матур яңгырашлы булсын дигән фикергә килдек. Шулай бер яңгырлы язгы көндә, Себердән КАМАЗ төзелешенә эшкә килгән Шәүкәт Сибгатуллин (шагыйрь Шәүкәт Гаделша) манма су булып килеп кереп, шатлыгыннан: «Таптым, егетләр, «Ләйсән» дип кушыйк берләшмәгә исемне» – дип кычкырып җибәрде. Бу исем һәркемнең күңеленә хуш килеп, бертавыштан риза булдык.

Без, «Ләйсән» әдәби берләшмәсе әгъзалары, язучылар белән гел аралашып яшәдек. Шәһәребездә үткәрелгән төрле чараларда, авылларда үткән әдәби-музыкаль кичәләрдә язучылар белән бергә без «Ләйсән»леләр дә чыгыш ясадык. Ул елларда республика, шәһәр матбугатында үткән бәйгеләрдә катнашып, диплом, мактау кәгазьләренә лаек булдык. Бик күпләребез «КАМАЗ төзелеше ударнигы» дигән исемгә дә лаек булды. Ул елларда туган бер шигыремнән өзек:

Күз яшьләрен түгә-түгә,
Төзедек нурлы кала,

Шуңа күрә матур була,
Шуңа күрә батыр була
Чаллыда туган бала.

Чаллы – КАМАЗ, КАМАЗ – Чаллы, –
Игезәкләр шикелле.
Чаллы – КАМАЗ кешеләре,
Корыч аттан көчлеләре,
Бигрәкләр дә сөйкемле.

Ядкәр булып җырлар калсын
Дөньяны аклый торган.
Бездән күчкән рухи көчне,
Бездән күчкән рухи хисне,
Югалтмый саклый торган.

Югалтмый саклый торган.

КАМАЗ төзелеше елларында Татарстан Язучыларының Чаллы бүлекчәсен талантлы язучы Эдуард Касыймов җитәкләде. Э. Касыймов гаиләсендә ике тапкыр булганым исемдә: берсе – 50 яшьлек гомер бәйрәмен үткәргәндә, икенчесе – соңгы юлга озатканда. Язучыны соңгы юлга озатканда мондыйрак шигырь юллары туган иде:

Соңгы нурын сирпеп кояш бата,
Балкып чыгар тагын төн үткәч.
Табигатьтә язлар кире кайта,
Тик кешеләр кайтмый, бер киткәч.

Киткән кеше бәлки сизгәндер дә,
Калганнарга төшә авырлык.
Үлгәннәрнең рухын балкытырлык,
Исәннәргә кирәк сабырлык.

Бу шигыремне Кадыйр Сибгатуллин укып чыккач: «Сәлимә, син шундый фәлсәфи шигырьләр күбрәк яз», – дип киңәш биргән иде.

Шигырьләрнең төрлесен язарга туры килде, бигрәк тә КАМАЗ чорларында. Шул елларда мин хәзерге «Рябинушка» бистәсеннән өй сатып алдым. (ул елларда «Айсу» бистәсе дип атала иде, чөнки коры ялан: су да, ут та юк иде). Мин иҗатым өчен Казан һәм Чаллы язучыларына бик рәхмәтлемен. «Кызлар җыры» дигән китапта шигырьләрем басылып чыккач, «Үзеңнең аерым китабыңны чыгар» дип, барысы да ярдәм кулы сузарга теләделәр. Илдар Юзеев бер килүендә: «Китаплык материал туплый алсаң, мин ярдәм итә алам», – дип өметләндерде. Хәтта Әлмәт язучылары Энҗе Мөэминова белән Саҗидә Сөләйманова да ярдәм итәргә теләкләрен белдерделәр. Саҗидә апа Сөләйманованың миңа язган хатлары архивымда саклана. Мондый юллар бар:

*«... Саумы, Сәлимәкәй! «Новый мир» журналында шигыреңне күреп, бик сөендем. Барыгыз өчен дә бик шатмын. Периферияднән эшче поэмасы баш калкыта. Иптәшләрнең дә шатлыгын чын күңелдән уртаклашам. «Казан утлары»ның 3нче санына Чаллы шагыйрәләренең шигырьләре кергән, биш авторның. Синең дә шигырең бар. «Сәлимәнең шигырьләре бик тормышчан, шулай язып торсын» дигән Рәдиф Гаташ. Акрынлап җыентык әзерлә. Тәнкыйтьләсеннәр, усалрак әйтсеннәр, хәтта гаделсез әйтсеннәр, барыбер уйланырга урын кала. Ниндие язылса, шундыен яз. Язылганда – яз гына...*

*15 декабрь 1977 ел».*

Хатлар, күп алар. Саҗидә Сөләйманова белән гомеренең соңгы көненә кадәр аралашып яшәдек. Үлемен ишетү тетрәндерде. Ул елда туган шигырь юлларымны ишеттерәсем килә:

Ул – бер үзгә җан иде шул,
Моңы китми йөрәктән.
Бер явыз көч алып китте
Без яшәгән тирәктән.

«Үлде» диләр, ышанмыймын,
Ул бит илаһи, көчле.
Җырларыннан кабындым мин
Давылдагы ут төсле.

Синдәдер ул, Әлмәт, синдә,
Төшләремә керде бит.
Канат кагып җилкенгәнен
Бөтендөнья күрде бит.

Изгеләр күккә аша ди,
Хактыр ла, дуслар, хактыр.
Күктә йолдыз яшен коя, –
Шагыйрә киткән чактыр.

«*Күктә йолдыз яшен коя*»

Вакыйгалар бер-бер артлы искә төшеп тора. Күренекле шагыйрь Равил Фәйзуллин төрле төбәкләрдән иҗат белән шөгыльләнүчеләрне җыеп очрашу үткәргән иде. Шагыйрь Хәсән ага Туфанның сөргеннән кайткан чаклары. Очрашуда, Туфан иҗатына гашыйк кеше буларак, аңа багышлап, юмор катыш язылган шигыремне укыдым. Анда шундый сүзләр бар иде:

Әйткән сүзе сөйкемле –
Йөрәгеңә үтемле,
Игеннәрне сугарган
Җәйге яңгыр шикелле.

Бүгенгедәй хәтеремдә. Хәсән ага миңа рәхмәт әйтте. Күзләреннән көзнең кояшлы – яңгырлы көнендәге кебек моңсулык сирпелә иде.

Хәтер сандыгында тагын бер вакыйга истә калган. Сибгат Хәкимгә 60 яшь тулу уңае белән, мәдәният сараенда зурлап кичә үткәрмәкчеләр, котлап сүз әйтерсең, диеп, мине дә чакырдылар. Шундый зур шагыйрьнең бәйрәменә буш кул белән барып булмас дигән уй килде башка. Ул заманнарда «Весенний» совхозы халыкны яшелчә, җиләк үстереп кенә түгел, матур чәчәкләр белән дә сөендерә иде. Иртән иртүк тордым да, КАМАЗ эшчеләренең вакытлыча яши торган «Молодёжный» поселогына йөри торган автобуска утырып шунда юл тоттым. Юл чатында төшеп калгач, бер-ике чакрым җирне җәяү атларга туры килде, әле сәгать сигезгә эшкә дә кайтып җитәргә кирәк. Кич белән өч кызыл канәфер чәчәген шагыйрьгә бүләк итеп, сүзләремне шигъри юлларга салып котладым:

Абыем, дисәм, абый түгел лә,
Җаныем, дисәм, җаный түгел лә.
Иҗатыгыз белән япь-яшь килеш

Яшисез Сез безнең күңелдә.

Кайсыларыдыр шунда, ярым шаярып: «Кызыл чәчәк бүләк итү –мәхәббәт билгесе, әллә гашыйк булдыңмы?» – дип төрттерделәр.

Ә мин талантлы кешеләрнең иҗатына һәрчак гашыйк булып яшәдем. Халык заллар тутырып, рухи байлык туплау өчен, әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашуга җыела. Балачактан бирле әдәбият-сәнгатькә тартылуымның тылсымлы көче бүген дә тынгы бирми. Халкым өчен булган борчылу, уй-фикерләремне дә көндәлек дәфтәренә язып саклыйм.

*2015 ел.*